# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы**
**Юшады авыл җирлегенең Түбән Юшады торак пунктында**
**халык җыены нәтиҗәләре турында**

**20.11.2023ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча 20.11.2023 елда үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге Түбән Юшады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2024 елда 2000 сум күләмендә үзсалым кертергә ризамы, *1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш*һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

- Түбән Юшады торак пунктында авылга керү авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 45 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 25 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларныц тавышлары түбәндәгечә бүленде:
халык җыенында катнашкан 25 кеше «РИЗА»позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде 0 җыенда катнашучылар.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар чыгарды:

1. Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Түбән Юшады торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге Түбән Юшады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә карар кабул ителгән дип расларга,*1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, күп балалы гаиләләр, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә*

*әгъзаларыннан тыш*- алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Түбән Юшады торак пунктында авылга керү авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча эшләр өчен түләү)-кабул ителде.

3. Юшады авыл җирлегенең мәгълүмати стендына урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http:// menselinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:/pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 10 көн эчендә нәтиҗәләрне игълан итү.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Юшады авыл җирлеге башлыгы ______________ И.Р.Ханов
(имза)